| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
| 1191-п | | 02.11.2021 |

«Турай» өске су алу корылмасында, «Сараз»
су суырту насос станциясендә, «Алабуга»
СЖТ МИЗ» АЖ су чистарту станциясендә
санитар саклык зоналарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 30 ноябрендәге 1316-п номерлы боерыгы нигезендә, 2019 елның 30 маендагы судан файдалану турында № 16-10.01.01.01.014-Х-ДЗИО-Т-2019-06083/00 килешүне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килүе турында 2021 елның 26 гыйнварындагы №16.11.11.000.Т.000128.01.21 дәүләт санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск районының Турай торак пунктында һәм Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә урнашкан «Турай» өске су алу корылмасында эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының, «Сарсаз» су суырту насос станциясенең, «Алабуга» СЖТ МИЗ» АЖ су чистарту станциясенең санитар саклык зонасы проекты нигезендә

боерык бирәм:

1. Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланган «Су белән тәэмин итү һәм эчә торган су үткәргечләре чыганакларының санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә әлеге боерыкның 1 нче

кушымтасындагы чикләрдә, әлеге боерыкның 2 нче кушымтасындагы территориядән хуҗалык өчен файдалану режимы белән «Турай» өске су алу корылмасында, «Сарсаз» су суырту насос станциясендә, «Алабуга» МИЗ» АҖ су чистарту станциясендә санитар саклык зоналарын билгеләргә.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И. Ткачук) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыятенә;

- «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФБУ филиалына, – санитар саклык зонасын билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;

- Татарстан Республикасының Менделеевск һәм Алабуга муниципаль районнары башкарма комитетларына.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы һәм Алабуга муниципаль районы башкарма комитетлары җитәкчеләренә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Менделеевск районының Турай торак пунктында һәм Алабуга районы территориясендә урнашкан «Турай» өске су алу корылмасының, «Сарсаз» су суырту насос станциясенең, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ су чистарту станциясенең санитар саклык зоналары чикләре турында, су алу скважиналарының саклык зоналары чикләрендәге территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештыру турында;

- территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә санитар саклык зоналарын билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2021 елның 2 ноябрендәге 1191-п
номерлы боерыгына 1 нче
кушымта

**«Турай» өске су алу корылмасында, «Сараз» су суырту насос станциясендә, «Алабуга» СЖТ МИЗ» АЖ су чистарту станциясендә санитар саклык зоналары чикләре**

«Турай» су алу җайланмасы хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен билгеләнгән һәм су алу җайланмасы су эчендә булган ике яклы төп үзәне төрендәге су алу корылмасын, 1 күтәрткеч насос станциясее, «Сарсаз» су суырту насос станциясен һәм су чистарту станциясен турыдан-туры үз эченә ала.

«Турай» су алу корылмасы Кама елгасының уң ярында, Түбән Кама ГЭС агымы буенча югарырак, Ык тамагы районында, Татарстан Республикасы Менделеевск районының Турай авылыннан 2 км ераклыкта урнашкан.

Су алу корылмасы Түбән Кама сусаклагычы акваториясенең су хуҗалыгы участогында (Кама елгасы) урнашкан – су хуҗалыгы кишәрлегенең коды һәм исеме: Су хуҗалыгы кишәрлеге 10.01.01.014. «Воткинск гидроузелыннан Түбән Кама гидроузелына кадәр Бүә, (чыганактан Карман гидроузелына кадәр), Иж, Ык һәм Агыйдел елгаларыннан тыш». География координаталары: төньяк киңлектә: $55^{0}56'20{,}7''$, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}36'16{,}9''$.

Су суырта торган «Сарсаз» насос станциясе «Турай» су алгычыннан 17 км төньяк-көнбатышта урнашкан.

Су чистарту станциясе Татарстан Республикасының Алабуга районында, «Алабуга» СЖТ МИЗ» АЖ сәнәгать мәйданчыгыннан һәм санитар-саклык зонасыннан читтә урнашкан.

Санитар саклык зонасының беренче поясы астындагы җир кишәрлегенең кадастр номеры:

1) «Турай» су алу корылмасы: 16:27:000000:1317, 16:27:090401:17, 16:27:090401:464;

2) Су суырта торган «Сарсаз» насос станциясе: 16:27:080701:83, 16:27:080701:317;

3) Су чистарту станциясе: 16:18:200201:22, 16:18:200201:804, 16:18:200201:105, 16:18:200201:474, 16:18:200201:29, 16:18:200201:806.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык сусүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

Су алу корылмасы Кама елгасы үзәнендә ярдан 85 метр ераклыкта урнашкан.

Санитар саклык зонасының беренче пояс чиге акватория буенча Кама елгасының уң яры буенча, 100 метр аралыкта үзлектән агучы сулар белән кисешкән урыннан, елга агымы буенча өскә һәм аска таба һәм 100 метр аралыкта капма-каршы ярга таба уза.

Санитар саклык зонасының янәшә ярыннан 100 метр ераклыкта сусаклагыч НПИ дәрәҗәсе буенча (62,0 мБС) уза.

Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясенең ян-як чикләре якын-тирә яр буенча 100 метр өскә таба һәм беренче күтәрелеш насос станциясе су үткәргечләреннән агым буенча аска таба урнашкан.

Якын-тирәдәге яр буенча су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы беренче пояс мәйданы 2,0 га тәшкил итә.

Беренче күтәрелеш насос станциясен урнаштыру санитар саклык зонасының беренче поясы чикләрендә планлаштырылган.

Якын-тирә яр һәм акватория буенча су алу корылмасының санитар саклык зонасында беренче поясның гомуми мәйданы 5,14 га тәшкил итә.

Койма чикләрендәге мәйданчык территориясе 5,21205 га тәшкил итә, шул исәптән беренче күтәрелеш станциясе бинасы мәйданы – 600 м$^2$.

Санитар саклык зонасының II поясы

Санитар саклык зонасының икенче пояс чиге түбәндәгечә уза:

- Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча су алу корылмасыннан 3 км ераклыкта. Территория буенча санитар саклык зонасының икенче пояс чиге яр буенча 3 км ераклыкта ике яктан да читтә урнашкан. Кырый чиге сусаклагыч НПУ (62,0м БС) булганда елга кисеме сызыгыннан 1000 метрлы аралыкта уза.

Санитар саклык зонасының икенче пояс территориясенең мәйданы 2578,2 га тәшкил итә, шул исәптән акваториянең мәйданы – 1978,2 га.

Санитар саклык зонасының III поясы

СанПиН 2.1.4.1110-02 кагыйдәләре нигезендә санитар саклык зонасының өченче пояс чиге сусаклагычта тулысынча икенче пояс чигенә туры килә.

Санитар саклык зонасының өченче пояс территориясенең мәйданы шулай ук 2578,2 га тәшкил итә, шул исәптән акваториянең мәйданы – 1978,2 га.

СанПиН 2.1.4.1110-02 кагыйдәләре нигезендә, су алу корылмаларының су алу корылмасы территориясеннән читтә урнашкан санитар саклык зоналары беренче поястан (катгый режимлы) тора.

Суүткәргеч корылмаларының (су суырта торган «Сарсаз» насос станциясенең) санитар саклык зонасында беренче пояс чиге  насос станциясе биналарыннан 15 метр ераклыкта кабул ителә.

Санитар саклык зонасының беренче пояс чиге су чистарту станциясе территориясендә урнашкан барлык су үткәрү объектларына 30 метрга тигез булган бердәм пояс итеп билгеләнә (булган коймалар чигендә 30 метрдан 300 метрша кадәр).

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2021 елның 2 ноябрендәге
1191-п номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**«Турай» өске су алу корылмасында, «Сараз» су суырту насос станциясендә, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ су чистарту станциясендә санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зонасының беренче поясы буенча чаралар

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану рөхсәт ителми.

1.3. Биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган урыннарда урнашкан, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен, аларны чыгарганда су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Теләсә нинди агынты суларны, шул исәптән су транспортының агынты суларын, шулай ук су сыйфатына йогынты ясый торган кер юдырту, су белән тәэмин итү һәм судан файдалануның башка төрләре рөхсәт ителми.

Беренче пояс акваториясе буйлар һәм башка кисәтү билгеләре белән чикләтеп алына. Суднолар йөри торган сулыкларда су кабул итү җайланмалары өстендә яктырту белән бакеннар куелырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Су белән тәэмин итү чыганакларын пычратучы объектларны финанслау чыганаклары белән тәэмин ителгән һәм дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән килештерелгән конкрет су саклау чараларын эшләп ачыклау.

2.2. Торак, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы объектларын яңа төзү өчен территория бүлеп бирүне җайга салу, шулай ук су белән тәэмин итү чыганагының агынты сулары белән пычрануның куркыныч дәрәҗәсен күтәрүгә бәйле булган гамәлдәге предприятиеләрнең технологияләренә үзгәрешләр кертүне килештерү.

2.3. Су белән тәэмин итү чыганагын, шул исәптән аның кушылдыкларын да кертеп, су җыю зонасында юынты суларны агызуга юл куймау.

2.4. Санитар саклык зонасы акваториясе чикләрендә барлык эшләр дә, шул исәптән ком, чуерташ чыгару, су төбен тирәнәйтү, дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелек үзәге белән килештереп, фәкать су алу корылмасы капкачында суның сыйфаты начарланмавын гидрологик хисаплап нигезләгән очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Сулыклар эвтрофикациясенә каршы көрәшүнең химик алымнарын куллану Россия Федерациясе дәүләт санитар-эпидемиология хезмәтенең уңай санитар-эпидемиологик бәяләмәсенә ия булган препаратларны куллану шарты белән генә рөхсәт ителә.

2.6. Суднолар йөргән очракта, судноларны, дебаркадерларны һәм брандвахтларны пычрак һәм суднолар эче парланудан барлыкка килә торган суларны һәм каты калдыкларны җыю җайланмалары белән җиһазларга; пристаньнәрдә агызу станцияләрен һәм каты калдыкларны кабул итү урыннарын корырга кирәк.

## 3. Икенче пояс буенча чаралар

2 нче бүлектә күрсәтелгән чаралардан тыш, өслектә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарындагы икенче пояс чикләрендә өстәмә чаралар үтәлергә тиеш:

3.1. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

3.2. Рөхсәт ителми:

зиратлар, үләт базлары, урыннарда санитария шартларын яхшырту кырлары, фильтрлаштыру кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм җир асты суларын микроб белән пычрату куркынычы тудырган башка объектларны урнаштыру;

ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;

төп кулланудагы урманнарны кисү һәм үзгәртеп кору.

3.3. Торак пунктлар һәм башка объектлар территорияләрен санитар төзекләндерү чараларын үтәү (канализация белән тәэмин итү, су үткәрми торган ташландык су чокыры ясау, өслек суларын читкә агызуны оештыру һ.б.).

3.4. Төп кулланылыштагы урманнарны кисү һәм реконструкцияләү башкарылмый, шулай ук агач әзерләү предприятиеләренә агачларны тамырдан һәм озак вакытлы файдаланудагы урманнарны кисү фондын беркетелми. Бары тик урманнарны тәрбияви һәм санитар кисү генә рөхсәт ителә.

3.5. Торлаклар урнаштыру һәм терлек көтүне, шулай ук сулыктан һәм җир кишәрлекләреннән, урман биләмәләреннән яр буе полосасында кимендә 500 метр аралыкта су белән тәэмин итү чыганагында суның сыйфаты начарлануга яки күләме кимүгә китерерлек итеп, башка төрле файдалануны тыю.

3.6. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан санитар саклык зонасының икенче поясы чикләрендә су коену, туризм, су спорты һәм балык тоту өчен файдалану өслектәге суларны саклауга карата гигиеник таләпләрне, шулай ук су объектларын рекреацияләү зоналарына карата гигиеник таләпләрне үтәү шарты белән, билгеләнгән урыннарда гына рөхсәт ителә.

3.7. Санитар саклык зонасының икенче поясы чикләрендә составында химик матдәләр һәм микроорганизмнар микъдары суның сыйфатына карата санитар гигиена кагыйдәләрендә билгеләнгән нормативларны арттырып җибәрә торган сәнәгать, авыл хуҗалыгы, шәһәр һәм явым-төшем суларын агызу тыела.

3.8. Юллар, җәяүле сукмаклары киселешендә санитар саклык зонасының икенче пояс чикләре махсус тамгалы баганалар белән билгеләнә.

Министр урынбасары
Е.А. Тарнавский ______________________________

Минерал-чимал һәм
су ресурслары идарәсе җитәкчесе
А.М. Чинарев ______________________________

Хокукый тәэминат бүлеге башлыгы
А.И. Ткачук ______________________________

Каты файдалы казылмалар
геологиясе бүлеге башлыгы в.б.
Р.В. Гафуров ______________________________